Син лаеклы, газиз укытучым
Рәхмәтләрнең иң-иң җылысына.
Син лаеклы, газиз укытучым
Хөрмәтләрнең иң-иң олысына.

Җир йөзендә иң-иң матур теләкләрне
Сорасалар, багышларга кемгә, диеп,
Үзенә бик күп йөрәкләрне әсир иткән
Укытучыга, дияр идем, башым иеп.

**Хөрмәтле укытучыбыз Зайнак абый!** Сезне ихлас күңелдән олы юбилей - 90 яшь тулган көн белән котлыйбыз. Ходай Тәгалә биргән гомерегезне тазалыкта-саулыкта, Әнисә апа белән иңне-иңгә куеп тигезлектә, балаларыгызның кадер-хөрмәтендә, күп санлы укучыларыгызның, авылдашларыгызның күңел җылысын тоеп яшәргә насыйп итсен Сезгә.

Безнең буын укучыларына бәхетле өлеш тиде - без Бәзәкә урта мәктәбенең бердәм һәм көчле коллективы көнне төнгә бәйләп эшләгән заманда белем алдык. Ул чор укытучыларының кайсының гына исемен атасаң да – зур хәрефләр белән язылган МӨГАЛЛИМНӘР Сез. Сез таләпчән, әммә гадел укытучы булдыгыз.Сездән алган төпле белем, акыллы киңәшләр безне гомер буе саклап килде. Инде үзебезнең чәчләргә чал керсә дә, без Сезне онытмадык. Сезне һаман да сагынабыз, тирән мәгънәле сүзләрегез һаман да истә. Без Сезгә күңел тынычлыгы, бәхетле картлык телибез. Ренат Харисның "Кеше кайчан матур була?" шигыре нәкъ Сезнең хакта язылган кебек. Ул Сезгә "Бәзәкә- туган авылым" сайты укучыларының рәхмәте һәм иң изге теләкләре булып ирешсен.



Кеше кайчан матур була?
Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта-
Башкаларны чакырганда
Үзе яккан учакка.

Ятлар белән көрәшкәндә
Күңеле җылынганда.
Шул җылылыкның рәхәтен
Җаны белән тойганда.
Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта:
Ерак дустын очратканда
Елаганда кочаклап.
Җырлаган чакта җырының
Моңында эрегәндә,
Бәхеткә таба чапканда
Башкага юл биргәндә.
Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә:
Иң кыен вакытында да
Тормышка гашыйк хәлдә.
Сөйгән ярын югалтса да,
Сөюен саклаганда,
Иң гөнаһлы гыйшыкның да
Сафлыгын аклаганда.
Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә:
Шигырь тыңлаган чагында,
Уйга чума белгәндә.
Мәхәббәтен сүзсез генә
Аңлаткан мизгелендә,
Бәхет белән сөйләшкәндә
Бәхетнең үз телендә.
Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт:
Иле өчен, халкы өчен
Яшәгәндә җан атып.
Замананың авырлыгын
Иңнәренә алганда.
Олы данга ирешеп тә,
Кече булып калганда.

Гөлия Хисаметдинова (Мөхәмәтгәрәева)